МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.03.2017 Казан шәһәре № под-396/17

«Иң яхшы билингваль балалар бакчасы»
гранты турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын раслау турында» 2015 ел, 25 сентябрь, 707 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен өйрәтү буенча мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының иң яхшы педагогик коллективларын ачыклау һәм бүләкләү максатларында б о е р а м:

1. «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» грантын гамәлгә кую.

2. Кушымта итеп бирелә торган документларны расларга:

2.1. 2017 елда «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» грантына (алга таба- Конкурс) Конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планы

2.2. «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турында Положение.

3. Конкурсны 2017 елның 17 апреленнән 1 маена кадәр оештырырга һәм үткәрергә.

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы затларга, әлеге боерыкның 2.1 пункты белән расланган планны үтәүне тәэмин итәргә.

5. Бухгалтерлык исәп - хисап бүлегенә (Г. Ф. Гатиятуллина) конкурсны оештыруны һәм уздыруны финанслауны тәэмин итәргә.

6. Мәктәпкәчә белем бирү бүлегенә (Э. А. Измайлова) өч эш көне эчендә, боерыкны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына, дәүләт теркәвенә җибәрергә.

7. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, министр Э.Н.Фаттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
10.03. 2017 № под-396/17
боерыгы белән

2017 елда «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» Грантын алуга конкурс әзерләү һәм үткәрү буенча
Чаралар планы

| № | Чара исеме | Үткәрү срогы | җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Конкурс әзерләү һәм үткәрү белән гомуми җитәкчелек | 2017 елның март - май айлары | Мухаметов И. Р.<br>Федорова Т. Т. |
| 2 | Конкурс үткәрү буенча сметаны төзү | 2017 елның 25 мартына кадәр | Гатиятуллина Г.Ф<br>Имамова Г. К. |
| 3 | Республика конкурс комиссиясе составын, эксперт комиссиясе составын раслау | 2017 елның 5 апреленә кадәр | Федорова Т. Т.<br>Измайлова Э. А |
| 4 | Грант алуга сайлап алу конкурсы турында белдерү | гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланганчы 10 көннән дә соңга калмыйча | Республика конкурс комиссиясе |
| 5 | Грант алуга сайлап алу конкурсында катнашу өчен гаризалар кабул итү | 2017 елның 16 апреленә кадәр | Республика конкурс комиссиясе |
| 6 | Эксперт комиссиясенең Грант алырга дәгъва кылучы мәгариф оешмаларына чыгу графигын төзү | 2017 елның 16 апреленә кадәр | Измайлова Э. А.<br>Хисамиева Й..Ш.<br>Манюрова Г. Х |
| 7 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында "Грант алучыларның расланган исемлеге" турында норматив-методик материалларны урнаштыру. | бәйге үткәрү дәвамында | Кравцов А.А.<br>Галявеева Г.Х |
| 8 | Эксперт комиссиясе эшен оештыру | 2017 елның 17 апреленнән 1 маена кадәр | Федорова Т. Т.<br>Измайлова Э. А.<br>Асадуллин М. Х. |
| 9 | Грант алучылар исемлеген формалаштыру, конкурс сайлап алу нәтиҗәләрен игълан итү | 2017 елның 3 маена кадәр | Республика конкурс комиссиясе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | Бәйгене үткәрү көннәрендә фото һәм видеога төшерү. массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан конкурс барышын яктыртуны оештыру. | 2017 елның 17 апреленнән 1 маена кадәр | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәте |

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
10.03. 2017 № под -396/17
боерыгы белән

**“Иң яхшы билингваль балалар бакчасы” гранты турында**
**Положение**

## 1. Гомуми положениеләр

1.1. «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» (алга таба - Грант) гранты Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела.

Чарада грантны гамәлгә куючы (грант бирүче), Грантка дәгъва кылучы һәм грант алучы катнаша.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - министрлык).

Грантка дәгъва кылучы - Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген алып баручы, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмасы (алга таба - мәгариф оешмасы).

Грант алучы - әлеге Положение белән билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган, конкурс сайлап алуы узган һәм беренче 20 урынны алган белем бирү оешмасы.

Грант - Грант алучыларга, мәктәпкәчә төркемнәрнең сыйфатлы үстерешле предметлы-тирәлеген булдыру, педагогик коллективның һөнәри үстешенә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен, бер тапкыр бирелә торган 500 000 (биш йөз мең) сум күләмендә акчалата бүләк.

Грант алучы 5 елга 1 тапкыр грантта катнашырга хокуклы.

1.2. Гранта сайлап алу конкурсының максаты – мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Татарстан республикасы дәүләт телләренә өйрәтүнең сыйфатын үстерүне стимуллаштыру, әлеге юнәлештә белем бирү оешмаларының уңай тәҗрибәсен тарату, Татарстан республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру.

Конкурс сайлап алуының бурычы - мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирүнең югары сыйфатын тәэмин итүче мәгариф оешмаларын ачыклау һәм бүләкләү.

## 2. Грант алуга Гаризалар кабул итү һәм сайлап алу өчен конкурс үткәрү тәртибе

2.1. Грант алуга Конкурс Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

2.2. Грант бирүче гаризалар кабул итү вакыты тәмамланырга 10 көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, Грант (алга таба - Конкурс) алуга конкурс сайлап алуы турында игълан итә.

2.3. 2017 елның 16 апреленә кадәр грантка дәгүва кылучылар конкурста катнашырга Министрлыкның Chulpan.Haidarovna@tatar.ru электрон адресына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе (бүлеге) җитәкчесе тарафыннан расланган гариза бирәләр. Гаризада белем бирү оешмасының исеме, адресы, тәрбия һәм белем бирү теле, төркемнәр һәм тәрбияләнүчеләр саны күрсәтелә.

2017 елның 16 апреленнән дә соңга калып гариза тапшырган очракта, грантка дәгъва кылучы конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.4. Конкурсны оештыру-методик тәэмин итүне һәм уздыруны рәис, җаваплы сәркатиб һәм республика комиссиясе әгъзалары составында Республика конкурс комиссиясе (алга таба - Республика комиссиясе) гамәлгә ашыра

2.5. Республика комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2.6. Республика комиссиясе:

массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар аша конкурсны үткәрү шартлары, тәртибе һәм сроклары турында игълан итә;

катнашучылардан гаризалар кабул итә;

эксперт комиссиясе эшен туплый һәм оештыра;

конкурс үткәрүне оештыра; конкурска йомгак ясый;

конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыра;

конкурс нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны оештыра.

2.7. Республика комиссиясе карарлары, алар өчен катнашучыларның күпчелеге тавыш биргән оярακта .кабул ителгән дип санала, Тавышлар саны тигез булса Республика комиссиясе рәисенең тавышы хәл итүче булып тора.

2.8. Грантка дәгъва кылучыларның конкурс критерийларына туры килүенә экспертиза ясау өчен эксперт комиссиясе рәисе һәм әгъзалары составында эксперт комиссиясе төзелә.

2.9. Эксперт комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2.10. Республика комиссиясе, эксперт комиссиясе утырышлары кирәк булган саен үткәрелә һәм алар комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып санала.

2.11. Экспертлар сыйфатында:

Министрлык вәкилләре;

мәгариф идарәсенең муниципаль органнары вәкилләре;

педагогик хезмәткәрләргә өстәмә профессиональ белем бирү региональ белем бирү уку йортлары;

педагогик уку йортлары;

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары педагоглары җәлеп ителә

2.12. Экспертиза вакытында тәэмин ителә:

бәяләү критерийлары нигезендә белем бирү оешмасы эшчәнлеген бәяләүнең объектив булуы;

конфиденциальлек (шул исәптән конкрет катнашучыны бәяләүдә катнашмаган эксперт комиссиясе әгъзаларына карата да).

2.13. Эксперт комиссиясе 17 апрельдән 1 майга кадәр белем бирү оешмаларына барып, әлеге Нигезләмә нигезендә, Грантка дәгъва кылучыларның эшчәнлегенә бәя бирә.

Баллар эксперт битләренә кертелә, экспертлар имзасы белән раслана һәм эксперт комиссиясе рәисенә тапшырыла.

Эксперт битләре нигезендә Грантка дәгъва кылучыларның рейтингы төзелә.

Эксперт комиссиясе рәисе һәм әгъзалары кул куйган Рейтинг республика комиссиясенә тапшырыла.

2.14. 2017 елның 3 маена кадәр Республика комиссиясе Конкурс йомгаклары буенча Грантка дәгъва кылучыларның рейтингында 1 нче 20 урынга чыккан 20 белем бирү оешмасыннан грант алучылар исемлеген төзи.

2.15. Грант бирүче 2017 елның 5 маена кадәр Министрлыкның hipp//mon.tatar.ru сайтында "Программалар һәм проектлар» бүлеге / «Укытучыларга грантлар» / «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы»/бүлекчәсендә грант алучыларның расланган исемлеген урнаштыра:

### 3. Грант алучыларны сайлап алу конкурсы критерийлары.

3.1. Конкурс белем бирү оешмаларына чыгып, Грантка дәгъва кылучыларның мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Татарстан Республикасы дәүләт телләренә өйрәтүне оештыру һәм эшнең нәтиҗәлелегенә урыннарга чыгып турыдан-туры бәя бирү формасында үткәрелә

3.2. Грант алуга сайлап алу конкурсы критерийлары:

балаларны татар (рус) теленә, Туган телгә өйрәтү буенча укыту - методик комплектларны (алга таба-УМК) гамәлгә ашыру эшенең, этномәдәни региональ компонентын тормышка ашыру буенча эшнең мәктәпкәчә тәрбия төп гомуми белем бирү программасында, белем бирү оешмасының үсеш программасында, еллык планда, чагылышы (максималь балл саны - 5 балл);

педагогларның балаларны татар (рус) телләрнә өйрәтү буенча эшчәнлеген планлаштыруы перспектив, календарь эш планнарына, программага туры килүе (максималь баллар саны-5);

белем бирү оешмасында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Татарстан Республикасының ике дәүләт теленә өйрәтүне контрольдә тотуны тәэмин итү (максималь баллар саны - 5);

мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирү буенча ата-аналар белән эш формаларының системалылыгы һәм төрлелеге (максималь баллар саны-5);

татар теле, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирү буенча квалификаөия күтәрү курслары узган педагогларның өлеше (максималь баллар саны-5);

педагогларның УМК эчтәлеген, УМК да күрсәтелгән сүзлек запасын белү дәрәҗәсе (максималь баллар саны-10);

мәктәпкәчә яшҗтәге балаларны татар (рус) теленә өйрәтүнең нәтиҗәлелеге, балаларның программада бирелгән лексик минимумны практикада куллана алуы (максималь баллар саны-10);

төркемнәрдә, кабинетларда этномәдәни предметлы - үстерешле мохит булуы, методик материаллар белән тәэмин ителеше (максималь баллар саны-10);

Балаларны Татарстан Республикасының дәүләт телләренә өйрәтү, төп белем бирү программасының региональ өлешен тормышка ашыруны күздә тоткан авторлык программалары, белем бирү оешмасы педагогларының методик эшләнмәләре булу (максималь баллар саны-5);

3.3. Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла. Эксперт комиссиясе әгъзалары конкурс нигезендә сайлап алуның һәр критерийга белем бирү оешмасына куйган баллар суммасы буенча, грантка дәгъва кылучылар рейтингын төзи.

3.4. «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты рейтингта 1-20 урын алган мәгариф оешмаларына бирелә.

## 4. Грантны финанслау

4.1. Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.